РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 06 2018г. №427

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы административ комиссия составын раслау турында

Татарстан Республикасының 2005 елның 30 декабреннән булган “Административ комиссияләр эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирү турында”гы Законын үтәү максатында Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар итә:

1. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршында административ комиссияне расларга (Кушымта №1)
2. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 22 апреленнән булган №12 карарын көчен югалткан дип санарга.
3. Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы административ комиссиянең эш Регламентын расларга (Кушымта №2).
4. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 26 мартыннан булган 62 санлы карарын көчен югалткан дип санарга.
5. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының http://jutaza.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче С.П. Самонина

18.06.2018 № 427
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
Кушымта №1

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы административ комиссия составы:

Самонина Светлана Петровна - Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе;

Мортазин Илгиз Марат улы –Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;

Латыйпова Золфия Мөрсәлим кызы – административ комиссиянең әйдәүче белгече, комиссиянең җаваплы секретаре.

Комиссия әгъзалары:

Зарипова Гүзәл Рәшит кызы – Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге әйдәүче белгече;

Нигъмәтуллин Тимур Илдус улы – “Җәмәгать тәртибен саклау буенча “Форпост” яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге” МБУ директоры.

18.06.2018 № 427
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
Кушымта №2

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламенты

Бу регламент Ютазы муниципаль районы административ комиссиясенең (алга таба – административ комиссия) эш тәртибен билгели

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Административ комиссия Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан оештырылды.

1.2. Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турында кодексы, Татарстан Республикасыныц административ хокук бозулар турында кодексы, Татарстан Республикасының 2005 елныц 30 декабреннән булган “Административ комиссияләр эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирү турында”гы 144 санлы Законын (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) һәм Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль-хокукый актларына ярашлы гамәлгә ашыра.

1.3. Административ комиссия даими эшләүче, Татарстан Республикасының административ хокук бозулар турында кодексында каралган административ хокук бозулар турында эшләрне карау өчен оештырылган коллегиаль орган булып тора һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы чикләрендә эшли.

1.4. Административ комиссия бурычлары булып һәр эшне административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексына һәм Россия Федерациясе Кодексына ярашлы төрле яклап, тулы, объектив һәм вакытында карау, чыгарылган карарны үтәүне тәэмин итү, шулай ук административ хокук бозуларны кисәтү тора.

1.5. Административ комиссия вәкаләтләре срогы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләре срогына әлеге административ комиссиянең беренче утырышы көненнән башлана. Билгеләнгән срок үткәннән соң, административ комиссия үзенец вәкаләтләрен административ комиссиянең яңа составының беренче утырышына кадәр башкаруны дәвам итә.

1.6. Административ комиссия әгъзасы вәкаләтләре вакытыннан алда Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда туктатыла.

1.7. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты, вакытыннан алда үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан административ комиссия әгъзасы урынына яңа административ комиссия әгъзасын элекке административ комиссия әгъзасы вакытыннан алда вәкаләтләрен туктату турында карар кабул иткән көннән соң бер айдан да соңламыйча билгеләләргә бурычлы.

1.8. Административ комиссия, административ комиссиянең тулы исеме булган мөһергә (печать) ия.

2. Административ комиссия эшен оештыру

2.1. Административ комиссия, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнүче административ комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, административ комиссиянең җаваплы сәркәтибеннән һәм административ комиссия әгъзаларыннан (алга таба – административ комиссия әгъзалары) тора.

2.2. Административ комисия әгъзалары үз вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Законына ярашлы гамәлгә ашыра.

2.3. Административ комиссиянең персональ һәм сан составы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә, ул биш кешедән ким булмаска һәм так санны тәшкил итәргә тиеш.

2.4. Даими штат нигезендә административ комиссия составына административ комиссиянең җаваплы сәркатибе керә. Административ комиссиянең башка әгъзалары административ комиссиядә, бу Регламентның 2.5 пунктында каралган очраклардан тыш, түләүсез эшли.

2.5. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карары буенча, административ комиссиянең башка әгъзалары үз бурычларын җирле бюджет акчасы хисабына түләүле нигездә дә башкара ала.

2.6. Административ комиссия рәисе административ комиссия әгъзаларының, шулай ук административ комиссия рәисе һәм җаваплы сәркатип арасында вазифаларны бүлә, Татарстан Республикасы Законы биргән вәкаләтләр чикләрендә аларның бурычларын билгели.

2.7. Административ комиссия рәисе административ комиссия әгъзаларының, шулай ук административ комиссия рәисе урынбасарының һәм җаваплы сәркатибенең квалификациясен күтәрү буенча эшне оештыра.

2.8. Административ комиссия тарафыннан гражданнарны кабул итү тормышка ашырылырга мөмкин. Килүчеләрне кабул итү тәртибе административ комиссия рәисе күрсәтмәсе белән билгеләнә.

2.9. Административ комиссия адресына кергән гражданнарның һәм юридик затларның шикаятьләре һәм мөрәҗәгатьләре гамәлдәге закончалыкта билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карап тикшерелә.

2.10. Административ хокук бозулар буенча эшләр административ комиссиядә саклана һәм 3 ел үткәннән соң Ютазы муниципаль районының архив бүлегенә тапшырыла.

## 3. Административ комиссияне чакыру һәм утырыш уздыру тәртибе

3.1. Административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерү Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексында билгеләнгән тәртиптә административ комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.2. Административ хокук бозулар турында эшләр, Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексында билгеләнгән тәртиптә, административ комиссия тарафыннан утырышларда карап тикшерелә. Административ комиссия утырышы уздыруның датасы, вакыты һәм урыны турында карар, административ хокук бозулар турында беркетмәләр һәм башка материаллар туплануга карап (әмма айга бер тапкырдан да сирәк түгел), аның рәисе тарафыннан кабул ителә, ул булмаганда - рәис урынбасары тарафыннан.

3.3. Административ комиссия утырышлары административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерү сроклары үтәлешен тәэмин итүче вакытка карап уздырыла.

3.4. Административ комиссиянең җаваплы сәркатибе административ комиссия әгъзаларын административ комиссия утырышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында административ комиссия уздыру көненә кадәр ике көннән дә соңламыйча алдан хәбәр итә.

3.5. Административ комиссия утырышында катнашу мөмкин булмаган очракта, комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм комиссия әгъзалары бу турыда административ комиссиянең җаваплы сәркатибенә административ комиссия утырышына кадәр бер эш коне алдан хәбәр итәргә тиеш.

3.6. Административ комиссия утырышы анда административ комиссия әгъзаларының билгеләнгән санының өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы була.

3.7. Административ хокук бозу турында эш буенча карар, билгеләмә (определение) утырышта катнашкан административ комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

## 4. Административ җәза бирү турында карарның үтәлеше

4.1. Административ комиссия тарафыннан чыгарылган карарлар Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексына ярашлы үтәлә.

4.2. Административ комиссия тарафыннан чыгарылган карарларны, билгеләмәләрне һәм гариза итүләрне (представления) эш производствосында катнашкан затларның, башка юридик һәм физик затларның үтәүләрен контрольдә тотуны административ комиссиянең җаваплы сәркатибе тормышка ашыра.

5. Административ хокук бозуларны кисәтү

5.1. Административ хокук бозуларны кисәтү максатында, административ комиссия үз эшчәнлеген эчке эшләр органнары, Федераль суд приставлары хезмәте Идарәсенең территориаль бүлекләре, Татарстан Республикасының юстиция министрлыгы, башка органнар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән координацияли.

5.2. Административ комиссия, рәис раслаган графикка ярашлы, күчмә утырышлар уздыра, шул исәптән, муниципаль авыл җирлекләрендә дә.

5.3. Административ комиссия профилактик эшне үз эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту һәм халык арасында аңлату эшләре уздыру юлы белән оештыра.